РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**24.05.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№22/5**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының
2020 елның 27 маендагы
47/5 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2021 елның 21 деабарендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**Карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы вазыйфаи затына карата карар кабул итү тәртибе турында» 2020 елның 27 маендагы 47/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында ялган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чараларына үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның икенче абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның икенче абзацында, 6 пунктның беренче абзацында, 7 пунктның беренче һәм өченче абзацларында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов